**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 9 августындагы 3332 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 26 декабрендәге 4609 номерлы**
**«Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез**
**бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ**
**регламентын раслау турында»гы карарына**
**үзгәреш кертү хакында**

2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 4609 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 252 номерлы һәм 2023 елның 29 мартындагы 924 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2.8.2.1 пунктының 8 пунктчасында «төзелгән территорияне үстерү турында» сүзләрен «территорияне комплекслы үстерү турында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**